| | |
|---|---|
| СОВЕТ КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575 | Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575 |

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

ел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

02.03.2020 д. Канаш № 66-302

«Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең 2020 һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 декабрендә кабул ителгән 64-292 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Канаш авыл җирлеге башлыгы Вальков Н.Н. 2020 елның 1 гыйнварына бюджетның ирекле калдыгын төзү һәм 2020 елга бюджет статьяларына үзгәрешләр кертү кирәклеге турында мәгълүматын тыңлап һәм карап тикшергәннән соң,

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең 2020 һәм 2021, 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 декабрендә кабул ителгән 64-292 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге бюджеты чыгымнарын классификацияләүнең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү» 8 Кушымтада:

- «Үзәк аппарат» «Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү сатып алу» 0104-9900002040-200 юлында «327,9» санын «322,9» саны белән алыштырырга;

- «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү» «Башка бюджет ассигнованиеләре 0113-9900002950-800 юлында «1,2» санын «6,2» саны белән алыштырырга.

1.2. «Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең 2020 елга бюджет чыгымнарының ведомство структурасы» 10 Кушымтада:

- «Үзәк аппарат» «Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү сатып алу» 357-0104-9900002040-200 юлында «327,9» санын «322,9» саны белән алыштырырга;
- «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымы түләү» «Башка бюджет ассигнованиеләре 357-0113-9900002950-800 юлында «1,2» санын «6,2» саны белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисади мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Башлыгы: Н.Н.Вальков